| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Старогришкинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Иске Гришкино авыл жирлеге Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.12. 2023 ел №122

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге Советының 2020 елның
08 апрельендагы 131 номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советының 2020 елның 08 апрельендагы 131 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классы чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru " Иске Гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм депутат этикасы буенча даими комитетка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев